**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы**

**Карар**

**№ 43** **26.09.2017ел.**

**Иске Кармәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы:

1. Иске Кармәт авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2017 елның 19 ноябрендә якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2018 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы :

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

I. торак пункт чикләрендә халыкны энергия белән тәэмин итүне оештыру:

эл сатып алу һәм урнаштыру. фонарь һәм бишенче чыбык

II. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- III су насосын сатып алу һәм урнаштыру. Торак пункт чикләрендә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

чүплекләрне рекультивацияләү

IV. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны кышкы тоту-урамны вак таш белән тутыру

V. көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларын җыю һәм чыгару эшчәнлеген оештыруда катнашу.

"ӘЙЕ" ЮК.

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт  авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум округын билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт  авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Кармәт  авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт  авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Кармәт  авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай районы, Иске Кармәт  авылы, Ленин урамы, 37 йорт;

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт  авыл җирлеге
Советы Рәисе: Ф.З.Мусабиков